**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Андреевка авылы торак пунктында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында**

**Карар (КАРАР)**

**2022 елның 24 ноябре** **№ 1**
**10.00**
**Андреевка авылы,**
**Совет урамы кибет янында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, 28.07.2004 елдагы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2022 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде .Бу җыенда түбәндәге сорау куелды:«2023нче елда Акбаш авыл җирлегенең Андреевка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән , мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү каралган:
- Андреевка авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 133 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 72 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 72 кеше тавыш бирде;
«юк» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде
гражданнар җыенында катнашучыларның 0 тыелды.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Андреевка авылы торак пунктында гражданнарның җыен нәтиҗәсе гамәлдә дип тану.

2. «Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Андреевка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү :

-Андреевка авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип санарга..

3. Әлеге карарны Андреевка авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында "Интернет" челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://bugulma.tatar.ru, "авыл җирлекләре" бүлегенең "Акбаш авыл җирлеге" бүлекчәсе)

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**" Акбаш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** _______________ **Р. Т. Хуҗиев**